РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«12» март 2020г. г. Альметьевск № 362

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2006 елның 19 маендагы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының муниципаль казнасы турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы 71 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Карарны норматив хокукый актларга туры китерелү белән бәйле рәвештә, Әлмәт муниципаль районының контроль-хисап палатасы тарафыннан үткәрелгән «2017-2019 елларда муниципаль торак фонды белән идарә итү һәм эш итү тәртибен саклау» аналитик чараларын исәпкә алып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы, «Әлмәт муниципаль районының Торак сәясәте һәм торак-коммуналь хуҗалык департаменты» муниципаль автоном учреждениесе Уставы, Әлмәт муниципаль районының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы турында Нигезләмә, Россия Федерациясе Торак кодексының 2 статьясы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2006 елның 19 маендагы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының муниципаль казнасы турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы 71 нче номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2009 елның 22 январендәге 305 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе (МУ) сүзләрен тиешле килешләрдә «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының җир һәм мөлкәт менәсәбәтләре палатасы» карар һәм кушымта тексты буенча алмаштырырга;

1.2. 1 бүлек «Гомуми нигезләмәләр» карарга кушымта:

1.2.1. 1.4 пунктта «Казна мөлкәтен формалаштыру һәм исәпкә алу (реестр алып бару), тиешенчә файдалануны, шул исәптән район муниципаль казнасы мөлкәтенә хезмәт күрсәтүне тикшереп тору» сүзләреннән соң «торак фондыннан тыш» сүзләрен өстәргә;

1.2.2. түбәндәге эчтәлекле 1.5 пункт өстәргә:

Зак. № 3775

«1.5. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Торак сәясәте һәм торак-коммуналь хуҗалыгы департаменты» муниципаль автоном учреждениесе Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары кысаларында һәм Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә тапшырылган мөлкәтнең торышын, эчтәлеген, максатчан һәм тиешенчә файдаланылуын, муниципаль торак фондына хезмәт күрсәтүен, шул исәптән, тапшырылган мөлкәтнең торышын тикшерүне һәм шартнамәләрнең шартлары үтәүне гамәлгә ашыра.

1.3. карарга кушымтаның «Муниципаль казнаны тәшкил итүче мөлкәтне тоту» 6 бүлеге 6.3 пункты түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Физик һәм юридик затларга файдалануга тапшырылмаган районның муниципаль казна объектларын тотуны һәм эксплуатацияләүне оештыру муниципаль мөлкәт милекчесе тарафыннан тәэмин ителә»;

1.4. «Муниципаль казнаның сакланышын һәм максатчан кулланылышын тикшереп тору» 8 бүлегендә:

1.4.1. 8.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.1. Өченче затларга биләүгә һәм аннан файдалануга тапшырылган районның муниципаль казнасы составына керә торган мөлкәтнең сакланышын һәм максатчан файдалануын тикшереп торуны, торак фондыннан тыш, «вәкаләтле орган» кулланучылар белән төзелгән шартнамәләр шартлары нигезендә гамәлгә ашыра.»;

1.4.2. 8.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.2. «Вәкаләтле орган» контроль барышында тапшырылган мөлкәтнең торышын һәм торак фондыннан тыш кулланучылар белән тезелгән шартнамәләрнең шартларын үтәүне тикшерә.».

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының икътисадый үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Закиров Ш.К.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов